Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күлле-Кимеавыл җирлеге Советы

## КАРАР

«02» октябрь 2017 ел. № 61

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 23 мартындагы «Җирле референдум турында» 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Күлле-Кимеавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, 2017 елның 22 сентябрендәге «Референдум үткәрүне оештыру турында» 15 номерлы Күлле-Кимеавыл башкарма комитеты карары«, 2017 елның 22 сентябрендәге «Референдум үткәрүне оештыру турында» 60 номерлы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советы карар **бирде:**

1. 2017 елның 19 ноябренә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2018 елда үзара салым кертү өчен 18 яшькә җиткән, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган Күлле-Кимеавыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 1000 (мең) сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрү белән килешәсезме?:

1. Күлле-Киме, Ары авыллары территориясен төзекләндерү һәм чистарт эшләре алып бару.

2. Авыл җирлеге территориясендә җирле әһәмияттәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге:

- төзелеш материаллары сатып алу, Ары, Бахтачы, Яңа Бәрәскә авыллары урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү;

3. Җирле әһәмияттәге автомобилҗ юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Күлле-Киме авылына янгын сүндерү өчен тагылма агрегат сатып алу
- Күлле-Киме авылына янгын сүндерү машинасы өчен җылы стоянка төзү

ӘЙЕ ЮК»

3. Күлле-Киме авыл җирлегенең сайлау комиссияләренә, гамәлдәге законнар нигезендә, «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

4. Аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны экономияләү очрагында, әлеге акчалар планлаштырылган эшләрне башкару өчен акча җитәрлек булмаган юнәлешләрне финанслауга юнәлтелә.

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру, «Этнә таны» район газетасында бастырып чыгару һәм http://atnya.tatarstan.ru рәсми сайтка урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль
районы Күлле-Кимеавыл җирлеге башлыгы Гәрәев Х.Х.